КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 12 май г.Казань № 328

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 22 апрель, 319 нчы карары белән расланган Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган

компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 22 апрель, 319 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 25 февраль, 97 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга, акушеркаларга, фельдшерлык һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларының шәфкать туташларына) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибенә, 7 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«медицина оешмаларында һәм аларның структур бүлекчәләрендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән расланган чираттагы финанс елына бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре гамәлгә ашырылган медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының үрнәк исемлеге нигезендә эшләнгән вазыйфаларның программа реестрын раслый;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин